СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.09.24 № 49/4

На № ________ от ____________

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 27 декабрендәге 916 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1721 номерлы карары нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау турында» 2013 елның 28 августындагы 23/10 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертергә:

- Башкарма комитет структурасында 1 штат берәмлеген – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегеннән төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге әйдәп баручы белгечен кыскартырга;

- әлеге штат берәмлеген – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегеннән төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге әйдәп баручы белгечен һәм аны тотуга җирле бюджеттан чыгымны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының территориаль органына бирергә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Совет рәисе урынбасары

Р.И. Закиров